**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Сарабиккол авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында 2021 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы**
**КАРАРЫ**

2022 елның 02 феврале № 1а

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Сарабиккол авылында узган халык җыенының 2021 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы карары текстындагы техник хатаны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегенең Сарабиккол авылында гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Сарабиккол авылында «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Сарабиккол авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында» 2021 елның 20 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәреш кертергә:

2 пунктны түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:
- Сарабиккол авылында балалар мәйданчыгы төзелеше

2. Әлеге карарны Лениногорск районы, Сарабиккол авылы Киров урамы 4А,йортта - хакимият бинасында, Киров урамы 3А - гомуми белем бирү мәктәбе бинасында, Пионер урамы 45 йорт - «Сатурн - Урал» ҖЧҖ адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Сарабиккол авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Г.Р.Гаделшина